УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Конституция суды бетерелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты указларына кушымтада бирелгән исемлек нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация классы турында вакытлыча нигезләмәне раслау хакында» 2000 елның 12 июлендәге ПУ-521 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестрының 5 өлеше;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында вакытлыча нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2012 елның 26 ноябрендәге ПУ-996 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында вакытлыча нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-297 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына 1 нче кушымтаның 4 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указына 1 нче кушымтаның 4 өлеше;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының квалификация класслары турында вакытлы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 7 июнендәге ПУ-401 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Конституция судында Татарстан Республикасы Президенты вәкилләре турында» 2001 елның 31 маендагы 42 номерлы боерыгы.

3. Әлеге Указ 2022 елның 31 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 17 декабрь
№ ПУ-889

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «_17_» _декабрендәге_
ПУ-_889_ номерлы Указына
кушымта

Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советын төзү турында» 1999 елның 13 сентябрендәге ПУ-719 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2000 елның 6 июлендәге ПУ-491 номерлы, 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-829 номерлы, 2001 елның 25 июнендәге ПУ-547 номерлы, 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-65 номерлы, 2002 елның 15 ноябрендәге ПУ-992 номерлы, 2003 елның 4 августындагы ПУ-563 номерлы, 2003 елның 12 сентябрендәге ПУ-719 номерлы, 2004 елның 21 июнендәге ПУ-461 номерлы, 2005 елның 28 маендагы ПУ-214 номерлы, 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 18 февралендәге ПУ-64 номерлы, 2006 елның 18 маендагы ПУ-179 номерлы, 2007 елның 17 августындагы ПУ-428 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-646 номерлы, 2010 елның 24 июнендәге ПУ-403 номерлы, 2011 елның 2 июнендәге ПУ-300 номерлы, 2011 елның 15 августындагы ПУ-504 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-910 номерлы, 2014 елның 15 октябрендәге ПУ-986 номерлы, 2015 елның 20 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2015 елның 7 июлендәге ПУ-624 номерлы, 2016 елның 15 ноябрендәге ПУ-1006 номерлы, 2017 елның 10 июнендәге ПУ-497 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 28 февралендәге ПУ-197 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 9 октябрендәге ПУ-613 номерлы һәм 2020 елның 11 апрелендәге ПУ-230 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы составыннан Ф.Г. Хөснетдиновны чыгарырга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибе турында» 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788

номерлы, 2015 елның 20 февралендәге ПУ-178 номерлы, 2016 елның 8 июлендәге ПУ-585 номерлы һәм 2022 елның 31 октябрендәге ПУ-773 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибенең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук мәсьәләләре буенча ведомствоара координация комитетын оештыру турында» 2004 елның 19 июлендәге ПУ-490 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 26 декабрендәге ПУ-517 номерлы, 2007 елның 30 апрелендәге ПУ-218 номерлы, 2007 елның 18 декабрендәге ПУ-688 номерлы, 2008 елның 12 маендагы ПУ-206 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-201 номерлы, 2009 елның 7 декабрендәге ПУ-649 номерлы, 2010 елның 15 февралендәге ПУ-69 номерлы, 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-617 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-890 номерлы, 2011 елның 19 апрелендәге ПУ-222 номерлы, 2012 елның 29 июнендәге ПУ-519 номерлы, 2013 елның 2 мартындагы ПУ-183 номерлы, 2013 елның 19 сентябрендәге ПУ-915 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 25 гыйнварындагы ПУ-47 номерлы, 2015 елның 20 февралендәге ПУ-179 номерлы, 2015 елның 8 маендагы ПУ-430 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге ПУ-1086 номерлы, 2016 елның 17 ноябрендәге ПУ-1016 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 10 августындагы ПУ-664 номерлы, 2018 елның 26 мартындагы ПУ-269 номерлы, 2018 елның 14 сентябрендәге ПУ-638 номерлы, 2018 елның 13 октябрендәге ПУ-728 номерлы, 2019 елның 4 мартындагы ПУ-155 номерлы, 2020 елның 10 февралендәге ПУ-72 номерлы, 2020 елның 22 июнендәге ПУ-358 номерлы һәм 2021 елның 25 августындагы ПУ-668 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Хокук мәсьәләләре буенча ведомствоара координация комитеты турында нигезләмәнең 2 пункты икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында» 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-512 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2014 елның 28 февралендәге ПУ-233 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы һәм 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-252 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм

кадрлар департаменты турында нигезләмәнең 11 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының Җыелма исемлеген раслау турында» 2006 елның 9 мартындагы ПУ-92 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 30 июнендәге ПУ-415 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-460 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-229 номерлы, 2013 елның 2 августындагы ПУ-705 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге ПУ-1031 номерлы һәм 2020 елның 11 мартындагы ПУ-164 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының Җыелма исемлегендә «Татарстан Республикасы Конституция суды рәисе», «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары» һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы» позицияләрен төшереп калдырырга.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 20 мартындагы ПУ-114 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 мартындагы ПУ-121 номерлы, 2010 елның 1 апрелендәге ПУ-183 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 1 февралендәге ПУ-74 номерлы, 2013 елның 21 сентябрендәге ПУ-925 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 21 октябрендә ПУ-950 номерлы, 2016 елның 26 ноябрендәге ПУ-1053 номерлы, 2017 елның 27 октябрендәге ПУ-976 номерлы, 2017 елның 25 декабрендәге ПУ-1156 номерлы, 2018 елның 14 февралендәге ПУ-165 номерлы, 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы, 2020 елның 15 октябрендәге ПУ-697 номерлы һәм 2021 елның 12 июлендәге ПУ-565 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты турындагы нигезләмәдә:

а) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктның унтугызынчы абзацында «Татарстан Республикасы Конституция судында,» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 15 маендагы ПУ-174 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы һәм 2019 елның 1 февралендәге

ПУ-50 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе турында Нигезләмәдә:

а) 7 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 8 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 15 маендагы ПУ-176 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы һәм 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе турында Нигезләмәнең 8 пункты икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 22 маендагы ПУ-184 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы һәм 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге турында Нигезләмәнең 9 пункты икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 24 маендагы ПУ-196 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге ПУ-1186 номерлы һәм 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе турында Нигезләмәнең 8 пункты икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

11. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 9 сентябрендәге ПУ-365 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-662 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы һәм 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы указлары

нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте турында нигезләмәнең 9 пункты беренче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

12. Татарстан Республикасы Президентының «Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2010 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 16 сентябрендәге ПУ-616 номерлы, 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-897 номерлы, 2011 елның 25 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2012 елның 10 мартындагы ПУ-187 номерлы, 2012 елның 11 июнендәге ПУ-458 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1073 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2014 елның 20 февралендәге ПУ-183 номерлы, 2015 елның 8 апрелендәге ПУ-378 номерлы, 2016 елның 31 мартындагы ПУ-323 номерлы, 2016 елның 11 июнендәге ПУ-527 номерлы, 2016 елның 5 октябрендәге ПУ-904 номерлы, 2016 елның 3 декабрендәге ПУ-1062 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 9 февралендәге ПУ-112 номерлы, 2017 елның 5 апрелендәге ПУ-288 номерлы, 2017 елның 6 маендагы ПУ-366 номерлы, 2017 елның 10 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2017 елның 19 июлендәге ПУ-628 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге ПУ-334 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге ПУ-407 номерлы, 2018 елның 24 августындагы ПУ-583 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге ПУ-762 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 21 маендагы ПУ-285 номерлы, 2019 елның 18 октябрендәге ПУ-632 номерлы, 2019 елның 5 ноябрендәге ПУ-668 номерлы, 2020 елның 4 июлендәге ПУ-383 номерлы, 2020 елның 11 августындагы ПУ-471 номерлы, 2020 елның 28 октябрендәге ПУ-714 номерлы, 2021 елның 18 февралендәге ПУ-154 номерлы, 2021 елның 20 декабрендәге ПУ-973 номерлы, 2022 елның 16 мартындагы ПУ-205 номерлы һәм 2022 елның 22 октябрендәге ПУ-767 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе составыннан Ф.Г. Хөснетдиновны чыгарырга.

13. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-236 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы һәм 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турындагы нигезләмәнең 8 пункты өченче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

14. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 31 гыйнварындагы ПУ-37 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның

26 июлендәге ПУ-693 номерлы, 2013 елның 3 декабрендәге ПУ-1176 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-987 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы һәм 2020 елның 4 мартындагы ПУ-137 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе турында нигезләмәнең 8 пункты беренче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

15. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-873 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 августындагы ПУ-684 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-232 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы ПУ-475 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында нигезләмәдә:

а) 4 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктта «, Татарстан Республикасы Конституция суды» һәм «, Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырырга.

16. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының рәсми һәм эш стиле элементларын булдыруның һәм аннан файдалануның визуаль стандартлары паспорты турында» 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-880 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1212 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасының рәсми һәм эш стиле элементларын булдыруның һәм аннан файдалануның визуаль стандартлары паспортының I кисәгендә:

а) 4 пунктның 3 пунктчасында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктның 4 пунктчасы дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе,» сүзләрен төшереп калдырырга.

17. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 18 ноябрендәге ПУ-1120 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 1 февралендәге ПУ-50 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмәдә:

а) 8 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

18. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 20 декабрендәге ПУ-1253 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе секретариаты турында нигезләмәнең 8 пункты өченче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга.

19. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыймәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыймәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга.

20. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-914 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-717 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы, 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы, 2020 елның 2 маендагы ПУ-266 номерлы, 2021 елның 2 июнендәге ПУ-425 номерлы һәм 2022 елның 10 мартындагы ПУ-196 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе составыннан Ф.Г. Хөснетдиновны чыгарырга.

21. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 1 февралендәге ПУ-48 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсе турында нигезләмәнең 7 пункты беренче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратында,» сүзләрен төшереп калдырырга.